ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙКОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21,e-mail:mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№__429____ от «_25__»____07___2018 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Башкарма комитетының
2018 елның 2февралендә кабул ителгән
94 нче санлы карарына үзгәрешләрһәм
өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында»2007 ел, 24 июль, ФЗ-209 нчы Федераль закон,Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"гы 2003 ел, 06 октябрь, 131 -ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында кечеһәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 ел, 21 гыйнвар, ТРЗ-7 нче санлы Татарстан республикасы законнарына нигезләнепТатарстан Республикасы Мамадышмуниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 2 февралендә кабул ителгән 94 нче санлы карары белән расланган "2018-2020 елларга Мамадыш муниципаль районнында кече, урта эшмәкәрлекне һәм хуҗалыкның кече формаларын үстерү" муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 9 бүлек, 2 п. 3 п.п. түбәндәге сүзләр белән тулыландырырга: "Дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" 5 апрель, 2013 ел, №44-ФЗ Федераль законталәпләре нигезендә"

1.2.Гомуми нигезләмә бүлегенең 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары – «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 ел, 24 июль, ФЗ-209 нчы Федераль законда билгеләнгән шартлар нигезендә кече предприятиеләргә, шул исәптән микропредприятиеләргә, һәм урта предприятиеләргә кертелгән хуҗалык итүче субъектлар (юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр)";

1.3.Гомуми нигезләмә бүлегенең 13 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"Авыл хуҗалыгы товары җитештерүчеләр һәм (яисә) шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнар кооперативы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы дип таныла".

2.Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары М.Р.Хуҗаҗановка йөкләргә.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов